**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге составына керүче Яңа Мәртле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

21.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Мертле авылында зиратны төзекләндерү, инвентарьны саклау өчен бина төзү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 158 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 80 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 76 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге составына керүче Яңа Мәртле авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Яңа Мертле авылында зиратны төзекләндерү, инвентарьны саклау өчен бина төзү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Мәртле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күшке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ А.В. Стрелков

Күшке авыл җирлеге
башлыгы __________________ А.В. Стрелков